**СОВЕТ КАЗАКЛАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Казаклар, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЗАКЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Казаклар авылы, Совет урамы, 5

Тел./факс: +7(84365) 63-4-30, e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**15 октября 2024 г.** **№ 113**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегендә бюджет процессы турында" 29.09.2021 ел, №39 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 30.09.2024 ел, № 02-01-26 мәгълүматы нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында хокук мониторингы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегендә бюджет процессы турында» 29.09.2021 ел, №39 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә (13.12.2021 ел, №47 карарлар редакциясендә) кертергә. 13.02.2024 ел №97, 16.08.2024 ел № 111) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. 10 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасында «тапшыра» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Казаклар авыл җирлеге башлыгы
Биектау муниципаль районы Р.Р.Сафин